КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1082

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2008 елда хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 7 июль, 478 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 12 март, 157 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында»;

преамбулада Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2008 елда хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибе турында» 2008 елның 30 апрелендәге 326 номерлы карары» сүзләрен «Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджет-

ларына һәм Байконур шәһәре бюджетына субвенцияләр бирү тәртибе турында» 2009 елның 4 февралендәге 97 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне сарыф итү кагыйдәләрен расларга.»;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктка «һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2008 елда хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны сарыф итү кагыйдәләрен яңа редакциядә (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» 2020 ел, 8 декабрь, 1105 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 3 июль, 538 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) теркәлгән 1 нче кушымтаның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин